БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ РАЙОН БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«28» 06 2022 ел № 206

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы территориясендә шәһәр яны автомобиль транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны каплау максатларында пассажир йөртүчеләргә субсидияләр бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексына үзгәрешләр кертү белән бәйле рәвештә һәм Балтач муниципаль районы Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының 2018 елның 24 октябрендәге 327 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы территориясендә шәһәр яны автомобиль транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны каплау максатларында пассажир йөртүчеләргә субсидияләр бирү тәртибенә (алга таба - тәртип) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 3 бүлекнең 3.1. пунктына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«- сайлап алуда катнашучылар экстремистлык эшчәнлегенә яки террорчылыкка катнашы булуы турында мәгълүматлар булган оешмалар һәм физик затлар исемлегендә яисә массакүләм юк итү коралы таратуга катнашы булуы турында мәгълүматлар булган оешмалар һәм физик затлар исемлегендә булырга тиеш түгел.»;

1.2. 7 бүлекнең 7.1 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7.1. Субсидияләр бирү тәртибен һәм шартларын үтәү, шул исәптән аларны бирү нәтиҗәләренә ирешү, шулай ук муниципаль финанс тикшерүе органнары тарафыннан Россия Федерациясе Бюджет кодексының 268.1 һәм 269.2 статьялары нигезендә тикшерүләр өлешендә субсидияләр алучыларга һәм Россия Федерациясе Бюджет кодексының 78 статьясындагы 5 пунктында күрсәтелгән затларга карата тикшерү субсидия бирүче бюджет акчаларының баш бүлүчесе (бүлүчесе) тарафыннан гамәлгә ашырыла.»;

1.3. Бүлеккә 4 статьясына 4.7. киләсе эчтәлектәге:

«4.7. Субсидия акчалары хисабына, югары технологияле чит ил җиһазларын, чималын һәм комплектлаштыру әйберләрен сатып алганда

(китерткәндә) Россия Федерациясенең валюта законнары нигезендә гамәлгә ашырыла торган операциялардән, шулай ук әлеге башка операцияләр акчаларын алу максатларына ирешүгә бәйле операцияләрдән тыш, чит ил валютасын сатып алу тыела.»;

1.4. Тәртипнең 2 нче кушымтасының 6.1 пунктында «һәм (яки) шартларны, максатларны һәм тәртиптә каралган субсидияләр бирү тәртибен үтәүне тикшерүләрне муниципаль финанс контроле органнары тарафыннан » сүзләрен «һәм Россия Федерациясе Бюджет кодексының 78 статьясындагы 3 пунктының 5 пунктчасында каралган тикшерүләрне дәүләт (муниципаль) финанс контроле органнары тарафыннан» сүзләренә алмаштырырга.».

2. Әлеге карарны pravo.tatarstan.ru "Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында" бастырырга һәм baltasi.tatarstan.ru Балтач муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Татарстан Республикасы
Балтач район башкарма комитеты
җитәкчесе вазыйфаларын башкаручы И.С. Галимуллин